Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге Советы

Карар

01.09.2020 ел № 136

Бюджет процессын оештыру өлешендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 15 статьясындагы 4 өлеше, «Чәчәкле авылҗирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, 2019 елның 16 июлендәге 95 номерлы Чәчәкле авыл җирлеге Советы карары нигезендә. «Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында», Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Чәчәкле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу өлешендә бирергә.

2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Чәчәкле авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 п. күрсәтелгән вәкаләтләрнең берөлешен Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән тапшыру турында килешүләр төзүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны билгеләнгән вакытта Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://spasskiy.tatarstan.ru/) хокукый мәгълүматның рәсмисайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Чәчәкле авыл җирлеге башлыгы: Ә.Н. Исмәгыйлева